


Яр Чаллы шәһәренең “Ф.Г.Әхмәрова исемендәге 4 нче номерлы шәһәр балалар сырхауханәсе (поликлиникасы)” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе 1979 нчы елның апрелендә шәһәр сәламәтлек саклау бүлеге боерыгы нигезендә ачыла.

1982 нче елның март аенда яңа типтагы бинага күчә. Бина сменасына 300 кеше кабул итүгә хисапланган, 64 участокны үз эченә алган 4 педиатрия бүлеге, тар белгечләр, тернәкләндерү -дәвалау һәм мәктәп белән мәктәпкәчә белем бирү бүлегеннән тора. Ул Яшьлек проспект, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан.

1983 нче елдан башлап поликлиниканы Флюра Гариф кызы Әхмәрова җитәкләде.

1984 нче елда поликлиникада сәламәт бала кабинеты ачылды.

1992 нче елның ноябрь аенда сырхауханә базасында шәһәр медик-психологик ярдәм хезмәте үзәге ачыла, аның эш тәҗрибәсе алга таба республика күләмендә уртаклашырга тәкъдим ителә.

1995 нче елда учреждениедә “Сонатал” перенатал тәрбия кабинеты эшли башлый, аның эше нигезендә, аңлы ата-ана һәм сәламәт бала тууны формалаштыру юнәлдерелгән, педагогика һәм социаль фәннәр академиясе әгъзасы М. Л. Лазарева методикасы ята .

1996 нчы елдан башлап поликлиникада көндезге стационар эшли: башта-14 ятакка, ә 2003 нче елдан - 20 ятакка исәпләнгән.

1998 нче елда 4 нче номерлы балалар шәһәр сырхауханәсенә Ф.Г. Әхмәрова исеме бирелде.

2010 нчы елның декабрендә сырхауханә базасында шәһәрнең «Балалар сәламәтлек үзәге» эшли башлый. Үзәктә комплекслы тикшеренүләр вакытында, организмның функциональ һәм адаптив резервларына бәя биргәч кенә шәхси сәламәтләндерү программасы төзелә.

2017 нче елда сырхауханәдә капиталь ремонт үткәрелде, заманча җиһазлар белән тулыландырылды: цифрлы ренген комплексы, физиотерапия һәм ультратавыш диагностикасы аппаратлары урнаштырылды, офтальмология һәм отоларингология кабинетлары җиһазландырылды. Учреждение "Уңайлы мохит" программасы буенча җиһазландырылган, мөмкинлекләре чикләнгән пациентларга уңайлы шартлар тудырылган.

Эшчәнлек барышында сырхауханә инновацион технологияләр базасы, балалар сәламәтлеген саклау һәм профилактикалау, сәламәтләндерү өлкәсендәге кайбер кызыклы башлангычларның инициаторы, медик-психологик хезмәт күрсәтү һәм пренаталь тәрбия бирү буенча алдынгы тәҗрибә базасы, медицина көллиятнең табиб-педиатрлары һәм студентлары өчен интернат-база булып тора.

Яр Чаллы шәһәрнең балаларга һәм яшүсмерләргә югары квалификацияле ярдәм күрсәткәне өчен, яшь ата-аналарга гигиеник тәрбия биргәне өчен, сырхауханә коллективы шәһәр администрациясе башлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

2018 нче елның апрель аеннан поликлиниканы баш табиб Галиев Юрий Марат улы җитәкли.